СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский", Мамадышский район, Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

"17" ноября 2020 г. № 4-2

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге №1-47 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 октябрендәге № 1-47 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә»;

1.2 3.3 пунктта «теркәлә һәм кертелә» сүзләрен « керү рөхсәт ителә» сүзенә алмаштырырга;

1.3 4.2 пунктта «җирлек башлыгы» сүзләреннән соң «яисә башка рәислек итүче зат» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2021 елның 1 гыйнвареннангамәлгә керә.

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык ,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге
Советы рәисе /Гиззатуллина В.А./